**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » 04 2021 № 113

Аксубаево

«Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә
хокукый сәләте чикләнгән дип танылган
балигъ булган гражданнарга һәм балигъ булмаган
гражданнарга карата опека һәм попечительлек
тармагында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
2018 елның 25 декабрендәге 732 нче карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 02.03.2021 № 315 боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 13.11.2020ел, № 1954 боерыгы белән расланган, Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә чикләнгән сәләтсез дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 02.03.2021 № 315 боерыгы нигезендә, шулай ук норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының ««Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган гражданнарга һәм балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек тармагында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»» 2018 елның 25 декабрендәге 732 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 26.02.2021 ел, № 67 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 нче Кушымтада:

«Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасында 2.5. пунктның «якын бәйләнешләре булмавын раслаучы документлар (гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, туу турында таныклык, никахлашу (аерылышу) турында таныклык һ. б.)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2.6. пунктның «Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

Гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

Опекага алынган затның милкендә булган мөлкәткә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРН) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба - ТР буенча Росреестры) күчермә.

Опекунның (попечительнең) һәм рентадательнең (опекунның) гаилә яки якын туганлык бәйләнешләре булмавын раслаучы белешмәләр (таныклык (белешмә), граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны раслаучы башка документ (туу, аерылышу) һ. б.).

Опекунның (попечительнең) рента бирүче белән гаилә яки якын туганлык бәйләнешләре булмавын раслаучы белешмәләр (таныклык (белешмә), граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алуны раслаучы (туу, никахлашу (аерылышу) һ.б.) башка документ.

Гариза бирүченең тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе шушы Регламентның 2.5. пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алынырга тиешле документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Гариза бирүчедән таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү кертүне раслаучы документлар, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, тапшыру;

№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдә баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне»

3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге таләпләрне җибәрә:

- гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда).

- опекага алынган затның милкендә булган мөлкәткә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсендә) күчермә.

- Опекунның (попечительнең) һәм рентадательнең (опекунның) гаилә яки якын туганлык бәйләнешләре булмавын раслаучы белешмәләр (таныклык (белешмә), граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны раслаучы башка документ (туу, аерылышу) һ. б.).

Ведомствоара гарызнамә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба -ВЭХС) каналлары буенча төзелә һәм җибәрелә.

ВЭХС каналлары буенча электрон документ формасында ведомствоара гарызнамәне формалаштыру һәм җибәрүнең техник мөмкинлеге булмаганда, ведомствоара гарызнамә кәгазьдә почта аша, факс буенча, почта яки курьер илтүе аша җибәрелә.

Ведомствоара гарызнамә № 210-ФЗ Федераль законның 7.2 статья таләпләренә туры китереп төзелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара гарызнамәләр җибәрү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев